РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ ТАКТАЛАЧУКСКОГО СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423751, село Такталачук,
ул. Г.Авзал, дом 48, Тел. 3-44-57

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАКТАЛАЧЫК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ

423751,Такталачык авылы, Г.Авзал ур.,
48 нче йорт. Тел.3-44-57

# КАРАР

**05.04.2024 ел** №7

**Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге башкарма комитетының «2022-2024 елларга Такталачык авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү программасы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законын, «2024 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 07 маендагы 204 номерлы, «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе милли үсеш максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указларын, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында, Актаныш районы прокурорының 2024 елның 18 мартындагы 02-08-03-2024/Прдп63-24-20920005/70 номерлы күрсәтмәсен карап, Такталачык авыл җирлеге башкарма комитеты:

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлегендә 2022-2024 елларга кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү программасының Такталачык авыл башкарма комитетының 09.02.2022 елның №6 карары белән расланган төп чараларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлек. Кече эшмәкәрлекне нәтиҗәле үстерү өчен хокукый базаны камилләштерү һәм административ киртәләрне киметү», түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «4. | Үз-үзенә эшләүче гражданнарга мәгълүмати-консультация һәм белем бирү хезмәтләре күрсәтү | «Профессиональ керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы һәм ярдәм чаралары алучы үз статусын теркәгән үзмәшгульлек гражданнары санын арттыру | Финанслаусыз |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | санын арттыру | |

1.2. 2 бүлек. Эшкәкәрлекнең инновацион үсеше (инфраструктураны үстерү, инновацион потенциалны гамәлгә ашыру, яшьләрне инновацион процесска җәлеп итү), түбәндәге эчтәлекле 2,3 пунктларын өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары һәм үз-үзләрен билгән гражданнар тарафыннан адреслы сайлап алу механизмы һәм читтән торып ярдәм чараларын һәм махсус сервислар алу мөмкинлеге булган цифрлы платформа турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге турында мәгълүмат | Ярдәм чаралары алган кече эшмәкәрлек субъектлары һәм үз-үзләренә эшләүчеләр санын арттыру | Финанслау сыз |
| 3. | Инновацион продукция җитештерүне булдыру һәм (яисә) киңәйтү максатларында кече инновацион эшмәкәрлек субъектларына грантлар алу мөмкинлеге турында мәгълүмат; | | |

1.3. 3 бүлек. Кече эшмәкәрлек субъектларына финанс-кредит һәм мөлкәт ярдәме, түбәндәге эчтәлекле 5-9 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «5 | Финанс ярдәмен алу мөмкинлеге турында мәгълүмат, шул исәптән «Корпорация «КУЭ» АҖ һәм региональ гарантия оешмалары күрсәтә торган ярдәмне дә кертеп | Ярдәм чаралары алган кече эшмәкәрлек субъектлары һәм үз-үзләренә эшләүчеләр санын арттыру | Финанслау сыз |
| 6. | Дәүләт һәм муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән объектлар арасыннан мөлкәткә (арендага яисә башка хокукларга) керүне тәэмин итү. | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ташламалы кредитлау программасы буенча 7% ставка буенча финанс ярдәме алу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү | | |
| 8. | КУЭ субъектларына җитештерү мәйданчыкларына һәм сәнәгать парклары, технопарклар биналарына керүне тәэмин итү;<br>КУЭ субъектларының конкурентлы сатып алуларда катнашуы өчен шартлар тудыру; | | |
| 9. | Россия икътисадый үсеш министрлыгы ярдәмендә кирәкле җиһазлар һәм эшли торган биналарда (шул исәптән бизнес-инкубаторларда һәм коворкингларда) җитештерү һәм офис мәйданнарын арендалау хокукларыннан файдалану һәм (яисә) шәхси биналардан файдаланган өчен аренда түләүләре буенча компенсация (Россия Федерациясе субъекты территориясендә әлеге ярдәм чарасын гамәлгә ашырганда); | | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Такталачык авыл җирлеге» бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче М.Т.Мансуров